2019 елның январь аенда татар халкы зур югалту кичерде - халкыбызның яраткан җырчысы Илһам Шакиров вафат булды. И.Шакиров үзенең 65 ел гомерен милләткә хезмәткә багышлаган күренекле шәхес. Күкрәгеннән ургылып чыккан моң чишмәсе белән татар күңелен сугарган артист гомеренең күп елларын гастрольләрдә үткәргән, һәм безнең якларны да читләтеп үтмәгән. Аның берничә тапкыр Бәзәкәгә килүе дә билгеле . Бүгенге язмада шул истәлекләрне сезнең белән дә уртаклашырга булдык.

Илһамның җырлавын 60-нчы елларда авыл халкы күбесенчә радиодан тыңлап һәм газета-журналлардан укып белә. Авылдашыбыз Шаргыя апа Ибәтуллина хәтерләве буенча И.Шакиров Бәзәкәгә иң беренче тапкыр 1965 елда гармунчысы белән генә килә. Әлбәттә, һәркемнең аның концертына киләсе, моң иясенең үзен күрәсе, җырын тыңлап хозурланасы килә. Ләкин барлык кешенең дә мондый мөмкинчелеге генә булмый. Бәлки шуңадыр, зур гаиләдән булган Габдуллина Хәерлевида исемле кыз аны авыл башына чыгып каршы ала һәм үзләренә квартирга кертә. Ул вакытта әле авылда иске агач клуб була, ләкин шулай да тамашачыларны сыйдырышлылыгы ягыннан кечкенә булмый. Илһам концертына халык агыла гына, клуб шыгрым тула.

Икенче тапкыр Илһам Бәзәкәгә концерт программасын күрсәтергә үзенең группасы белән килә һәм бу якынча 1967 елда була. Кунакчыл авыл халкы аны бу юлы да җылы каршылый.

Арабызда Илһам Шакировны якыннан белгән тагын бер кеше яши – ул авылыбызның олы хөрмәткә лаек кешесе Шәмсия апа Лотфиева. Шәмсия апа белән Илһам абыйның якыннан танышлыклары турында ишеткәнем бар иде. Ләкин күп чакларда талантлы кешеләргә кагылган мондый сүзләр уйдырма гына булып чыга. Илһам абый якты дөньядан киткән көннәрдә Шәмсия апа белән очрашкач бу турыда сүз кузгаттым, һәм Шәмсия апа Илһам белән дуслыклары хакында якты хатирәләре белән уртаклашты.

Шәмсия апа Минзәлә районы Калмыя авылында туып үсә. Әтисен ул бөтенләй хәтерләми, чөнки Бөек Ватан сугышына алынган Вәгыйз абый яу кырында ятып кала. Шәмсия белән сеңлесен әниләре ялгыз тәрбияләп үстерә. Урта мәктәпне күрше авылда уңышлы тәмамлаган Шәмсия апа Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керергә тели һәм керү имтиханнары тапшыру өчен Алабугага килә. Яшәү өчен студентларның тулай торагына урнаша. Төрле яклардан җыелган яшьләр кичләрен үзара аралашалар, күңел ачалар һәм егетләр тулай торагында искиткеч матур тавышлы җырчы егет булуы турында сокланып сөйлиләр. Шул арада җырчы егет кызлар ягына да килеп чыга. Бу егет Шәмсия апаның якташы, Ворошилов районы (хәзерге Сарман районы) егете Илһам була. Беренче тапкыр алар шунда күрешеп танышалар. Җиткән егет белән яшь кыз күңелендә беренче мәхәббәт хисләре уяна . Институтка укырга керү җиңелләрдән булмый - конкурс бик зур, бер урынга 12 кеше туры килә. Аттестатында бер 4 дән кала гел 5 ле генә булган Илһам дүрт имтиханын яхшы билгеләренә бирсә дә аны укырга алмыйлар, чөнки әтисе “халык дошманы” дип сөрелгән кеше бит. Беренче агым белән имтихан тапшырып бетергән Илһам авылларына кайтып китә. Бераздан Шәмсия апа да конкурстан үтә алмаслыгын аңлый һәм кире

авылларына кайтырга дип Алабугадан Чаллы пристаненә төшә. Шулчак Казанга китүче пароходка керергә әзерләнгән Илһам аны күреп ала һәм йөгереп каршына чыга. Яшьләр берничә сүз алышырга гына өлгерәләр. Илһам аңа укырга керү өчен Казанга китеп баруын белдерә, син дә Казанга укырга кил, бергә укырбыз дип чакыра. Шәмсия апаның Казанга чыгып китәрлек мөмкинчелеге дә, максаты да булмый. Ул Минзәлә медицина училищесына укырга керә. Беркадәр вакыт узганнан соң, инде Илһам белән аралар өзелде дип торганда, Казаннан 5-6 битле хат килеп төшә. Шәмсиясенең адресын Илһам барыбыр эзләп тапкан бит! Шуннан эчкерсез, якты хыяллар тулы хат алышу башлана.
Шәмсия апа училищеда яхшы уку белән бергә спорт белән дә шөгыльләнә. II-курста укыганда аларны Казанга Республика күләмендәге чаңгы ярышына алып баралар. Яшьләр тагын кыска гына вакытка булса да очрашалар, кинодан соң кичке Казан буйлап серләшеп йөриләр. Илһам аңа язган, әмма илтеп салырга җитешмәгән хатын шаярып-көлеп үзе укый. Ә икенче көнне саубулашып вокзалда озатып кала. Җылы эчтәлекле хат алышу дәвам итә.
Училищены тәмамлаганнан соң Шәмсия апа юлламаны Бондюг районына ала. Чөнки монда аның ерак туганы яши бит, ни генә дисәң дә чит җирдә үз кешесе. Әмма бу турыда нигәдер Илһам белән киңәшләшеп тормый. Аны эшкә Тойма авылына билгелиләр. Язмышлары шулай язылгандыр күрәсең, бирейдә ул кияүгә чыга.
Тагын бер тапкыр, бөтенләй очраклы рәвештә Шәмсия апа белем күтәрү курсларына Казанга укырга баргач кибет ишеге төбендә очрашалар алар. Монда да бер-берсен таныйлар, тукталып хәлләрен белешәләр.
...Гомерләр үтә, Илһам концертларына инде Шәмсия апа балалары, оныклары белән йөри. Ләкин Илһам кайда гына очраса да бу чибәр Минзәлә кызын таный.
Менә шундый якты бер мәхәббәт тарихы. Бу истәлекләрне тыңлагач уйлап куйдым, бәлки мәшһүр җырчының йөрәк ярасы да, бөтен халык мәхәббәтен яуларлык көч биргән илһамчысы да нәкъ менә Шәмсия апа булгандыр.

(Ш.Ибәтуллина, Ш.Лотфиева истәлекләрен Ф.Башарова язып алды)

Январь 2019 ел

Фотолар Ш.Лотфиева архивыннан алынды.

https://www.youtube.com/watch?v=5hiRtuABce4 **Илһам Шакиров: халык илһамы / Ильгам Шакиров: вдохновение народа. Ватандашлар/ Соотечественники ТНВ**



# Поет

# Ильгам Шакиров






Дорогая Шамсия
Мне очень приятно поздравить
и приветствовать тебя по случаю
годовщины Великого Октября!
Шлю тебе сердечный привет и
желаю наилучшие пожелания.
И. Шакиров Казань.

г. Казань. Памятник „Владимир Ульянов".
Фото Папкова И. С. Арт. „Фотохудожник" Татбытпромсоюза. Редактор Гладков.
ПФ 00116. 2-IX-1955 г. Заказ № 2503. Тираж 5000 экз. Цена 90 к. Арт. инв. „Полиграфист".

абый, бакчагыз чирәм җиргә әйләнгән, җимеш агачларыгызны чүп

әйберләре ялт итте, көлеп калды. Фирзилә минем Хәдичәмнең дәва-

та, организмнарын җимерә, төрле авырулар алып килә. Гомереңне

отставкадагы майор.
Украина, Ялта шәһәре.

Хәтер-хатирә

# “КАЗАНГА КИЛ, БЕРГӘ УКЫРБЫЗ”



Балалардан үскәч кем булырга теләүләрен сорасаң, күбесе: “Җырчы-йолдыз булам”, — ди. Даншөһрәтне балалар да ярата шул. Ярый ла, тавышлары булса... Алайса хәзер сәләтем юк дип тә, “ертыклы” җырлар дип тә тормыйлар, җырлыйлар да җырлыйлар. “Этнең койрыгы калыпта да тораймый” диләр, табигать биргән тавышың булмаса, юк инде ул...

Әлфис Кыямов дигән җырчыны бик яраткан идем, кызганыч, арабыздан иртә китте... Аның “Гөлфиям” дигән җыры бар. Яратам инде шуны, оныклар да кәрәзле телефоннарына шул җырны яздырганнар. “Әби, синең җырың”, — диләр дә, җырлаталар Әлфисне, ә мин җырлый-җырлый биим, күзгә яшь килә...

Тукта әле, затлы, якташ җырчы Илһам Шакиров турындагы истәлекләрне язарга утырган идем ләбаса. Аның җырларында сугышның ачы кайгысы да, якыныңны югалту ачысы да, ямьле яшьлек тә, яшисе килү — бөтенесе дә бар — гомереӊ буе оныта торган түгел.

...Казанга белем күтәрергә баргач, безне тулай торакка урнаштырдылар. Радиоалгычны ачып җибәрсәк, Илһам Шакиров җырлый: “Һаваларда оча ике аккош, канатлары җиргә коела...” Без яшь чакта яратып җырлый торган мәхәббәт җыры бит бу! Өрфиядәй җиңел болытларга “утырып”, хыялланып алдык. “Илһаметдин белән бергә укыдык, бергә уйнап үстек, иртә белән бозау арканларга бергә бара идек, — дип искә төшерде Сарман районының Яңа Буләк кызы. — Ул җырлап бара, җырлап кайта иде. Җырлап та куясың инде, җырчы булырсың син, дия идем мин аңа. Читәннәренә утырып, чабаталы аякларын селкеп, җырлап кала иде. Олы гәүдәң белән читәнне җимерәсең бит инде, дия идем”.

Шундый шәп җырчыны күрү бәхетенә дә ирештек: белдерү эленгән, Илһам Шакиров килә! Бүген Тукай районындагы Калмия авылы халкына бәйрәм: урамнарга җырмоң таралган, бөтенесе шушы илаһи очрашуны көтә. “Килгән, килгән!” — дигән хәбәрне бала-чага бик тиз таратты. “Фәгыйлә апаларга фатирга кергәннәр”. Күреп булмасмы дип, үсмерләр дә шунда кайнаша. 1962 ел бу. Безгә Гали Җәмлехановны — кечкенә гармуннарда уйнаучыны керттеләр.

Өйдә тыныч кына утырып булмый, күңел урамга тарта. Күрше Хөснижиһан әбинең дә тынычлыгы югалган бугай — бер керә, бер чыга. Менә берзаман әбиебез түзмәде, клубка таба китеп барды, ярты сәгатьләп торды. Аннан бик кәефле кәеф белән кайтты да, безгә тезеп китте: «Җырлаттым бит Илһамны! Бик шәп егет икән, йөзендә нурлар уйнап тора. Улым, Илһам, сине күрергә килдем, җырларыңны көн саен тыңлыйм, безгә кич чыгарга ярамый, миңа да җырлап күрсәт инде», — дидем. “Кара урман”ны җырлады. Аркасыннан сөеп: «Бәхетең булсын, балакаем, бу тавышың Аллаһы Тәгалә бүләгедер, җырла, халыкны сөендер», — дидем. Әбинең тәвәккәллегенә сокланып тыңладык.

Аллаһы Тәгалә Илһам Шакировка моңлы, көчле тавышны гына түгел, буйсын, чибәрлекне дә өеп биргән. Дөресен әйтим, без — җиткән кызлар, бөтенебез дә аңа гашыйк булдык. Илһамлы, матур җырлар мәхәббәткә сусауны да көчәйтә бит ул!

Бер серне дә ачарга җөрьәт итәм әле. Без (авыл яшьләре, аеруча кызлар) Илһам Шакировны бигрәк үз иттек. Чөнки аның яшьли сөйгән яры безнең авыл кызы: авылыбызның иң чибәре, иң сылуы Шәмсия иде. Зифа буйлы, чиста түгәрәк йөзле, толымнары тездән түбән кап-кара чәчле... “Алар чибәр нәсел”, — дия иде әнкәй.

Илһам Шакиров белән Шәмсия Алабуга пединститутына укырга баргач очрашканнар һәм берберсенә гашыйк булып, мәхәббәтләрен шактый вакыт күз карашы аша гына белдертеп йөргәннәр — әдәп-оятны белә торган заман бит. “Илһамның аттестатында бер генә “4”ле, калган билгеләре “5” иде, — дип искә ала Шәмсия. — Мин ике имтиханымны “3”кә бирдем дә, барыбер керә алмыйм инде дип, кайтып киттем. Илһам Казанга киткәндә мин аны озатып калдым. Син дә Казанга кил, бергә укырбыз, диде ул миңа. Ләкин мин Минзәлә медицина училищесына укырга кердем. Хатлар алыштык, сагыну, эчкерсез ярату турындагы хатлар — мәхәббәтебезнең шаһитлары...”

Укуны тәмамлагач, Шәмсияне Менделеевск районындагы Бәзәкә авылына эшкә җибәргәннәр. Авыл халкы аны бик яраткан, “врач апа” дип кенә йөрткән. Шулай итеп, Илһам белән аралар ерагайган, мәхәббәт сүрелгән. Шуннан Шәмсия кияүгә чыккан. Еллар узгач чибәр кыз чибәр әбигә әйләнгән. Хәзер Шәмсия өч баласына һәм оныкларына куанып яшәп ята.

**Гөлфия ӘҺЛИЕВА.**
**Тукай районы, Боерган авылы.**

